СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с. Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕҖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

2019 елның 5 июле № 2

**КАРАР**

**Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында**

Россия Федерациясенең 2003 елның 6 октябрендә чыккан «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 2131-ФЗ номерлы законы,Сеҗе авыл җирлеге Уставы һәм хокукый актлар проектлары турында фикер алышуда катнашуда Сеҗе муниципаль берәмлеге халкының хокукларын тәэмин итү максатында 2018 нчы елның 22нче октябрендә чыгарылган 72 нче номерлы Совет карары белән расланган "Сеҗе муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә"гә яраштырып, карар бирәм:

1."Сеҗе"муниципаль берәмлегендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карар проекты буенча җәмәгать тыңлауларын" 2019 елның 5 августына билгеләргә.

2. "Сеҗе"муниципаль берәмлегендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар"ны Арча муниципаль районы, Курса Почмак авылы,Мәктәп урамы,1нче йорт адресы буенча 2019 елның 5 августында 16.00 сәгатьтә үткәрергә.

3. Гражданнарның Сеҗе муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәрен һәм җәмәгать тыңлауларында катнашу турында язмача гаризаларын 5 августның 15.00 сәгатенә кадәр Арча муниципаль районы, Курса Почмак авылы,Мәктәп урамы,1нче йорт адресы буенча җибәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) , Арча муниципаль районының рәсми сайтында(arsk.tatarstan.ru) һәм Курса Почмак авылы,Мәктәп урамы,1нче йорт ,Сикертән авылы,Үзәк урам,14нче йорт,Сеҗе авылы,Мәктәп урамы,25 нче йорт адреслары буенча мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Сеҗе авыл
җирлеге башлыгы Г.М.Гибадуллина